АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2020 № ПР-163-2

г. Казань

Муниципаль милектә булган гидротехник корылмаларны карап тоту турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе урынбасары В. К. Козонков мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет) **карар итте:**

1. Совет рәисе урынбасары В.К. Козонковның муниципаль милектә булган гидротехник корылмаларны (алга таба – ГТК) тоту һәм эксплуатацияләү турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Муниципаль милектә булган ГТКларга үзәкләштерелгән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле матди-техник базасы булган оешма базасында ГТКны агымдагы карап тотуның бердәм системасын булдыру максатка ярашлы дип санарга.

3. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына ГТКны авыл җирлекләре милкеннән муниципаль районнар милкенә тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесына ГТК карап тоту нормативлары буенча исәп-хисап әзерләргә тәкъдим итәргә.

Вакыты: 2020 елның 31 мартына кадәр.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына ГТКны агымдагы карап тотуга нормативларны раслау һәм аларны 2020 елда гамәлгә кертү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать әзерләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г. Барышевка йөкләнә.

Рәис **Ә.С.Гобәйдуллин**